ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ЯУШИРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 53/1

Чистай муниципаль районы
Яуширмә авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Яуширмә авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Яуширмә авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 52/1 номерлы карары, Яуширмә авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 13 номерлы карары белән, Яуширмә муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2019 елда 200 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкаруда җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы:

- Яуширмә авылындагы юлларга ремонт ясарга (чокырларны күмәргә, щебенка сатып алырга, китертергә һәм җәяргә)

ӘЙЕ                    ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Яуширмә авыл җирлеге
башлыгы                                                  Л.Р.Гараева